МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.02.2019 г.Казань № 47

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 25 февралендә 5438 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының халыкка социаль ярдәм өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 04.02.2019 № 77 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 № 461, 09.11.2015 № 821, 07.06.2016 № 317, 20.07.2016 № 420, 28.11.2016 № 668, 27.02.2017 № 104, 08.06.2017 № 349, 28.05.2018 № 401, 18.09.2018 № 857 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.2 пунктта:

32 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32) мөрәҗәгать итү датасына уртача айлык кеременең күләме 20 000 сумнан артмаган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә булган торышында аталган федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, йә эше (хезмәте) өчен гомере буе акчалата түләү ала торган, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән хезмәт ветераннары;»;

35-40 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35) «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, картлык буенча яки эшләгән еллар өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле хезмәт стажы булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә булган торышында аталган федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, йә эше (хезмәте) өчен гомере буе акчалата түләү ала торган, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән затлар;

36) даими рәвештә читләр каравына мохтаҗ булган ялгыз пенсионерлар, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән, даими рәвештә читләр каравына мохтаҗ булган ялгыз гражданнар, 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин

итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән ялгыз гражданнар;

37) авыл җирлегендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче дәүләт ветеринария хезмәте белгечләре, шулай ук пенсиягә чыккан гражданнар, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнар, шулай ук 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән, авыл җирлегендә яши торган һәм Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан ветеринария хезмәте дәүләт учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән аталган белгечләр исәбендәге гражданнар;

38) авыл җирлегендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче социаль хезмәт дәүләт системасы социаль хезмәткәрләре, шулай ук пенсиягә чыккан гражданнар, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнар, шулай ук 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән, авыл җирлегендә яши торган һәм авыл җирлегендә урнашкан социаль яклау учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән күрсәтелгән хезмәткәрләр исәбендәге гражданнар;

39) авыл җирлегендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче педагогика хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе, социаль хезмәтләр дәүләт системасының социаль хезмәт күрсәтүче учреждениеләре хезмәткәрләре, шулай ук пенсиягә чыккан гражданнар, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнар, шулай ук 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән, авыл җирлегендә яши торган һәм Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында, Татарстан Республикасы мәдәният учреждениеләрендә, Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән аталган хезмәткәрләр исәбендәге гражданнар;

40) авыл җирлегендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче табиблар, провизорлар, урта медицина һәм фармацевтика белеме булган хезмәткәрләр, социаль хезмәтләр дәүләт системасының медицина хезмәткәрләре, турыдан-туры социаль-медицина хезмәтләре күрсәтү белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр, шулай ук пенсиягә чыккан гражданнар, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнар, шулай ук 2018

елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән, авыл җирлегендә яши торган һәм авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы медицина учреждениеләрендә, Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән күрсәтелгән хезмәткәрләр исәбендәге гражданнар.»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алучы документлар алына:

иминиятләштерелгән затка барлык дәрәҗә бюджетлардан социаль түләүләр күләме турында (субсидия-ташламаны ялгыз яшәүче пенсионерларга, хезмәт ветераннарына, Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга, авыл җирлегендә эшләгән һәм яшәүче белгечләр исәбендәге пенсионарларга билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына түләнгән түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр суммасы турында (субсидия-ташламаны хезмәт ветераннарына билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

федераль законнар нигезендә ай саен бирелә торган акчалата түләү алудан баш тарту турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең туктатылуы турында (субсидия-ташламаны хезмәт ветераннарына билгеләү өчен) (Россия Эчке эшләр министрлыгына);

хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында (субсидия-ташламаны хезмәт ветераннарына билгеләү өчен) (Россия Оборона министрлыгы);

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (субсидия-ташламаны хезмәт ветераннарына билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондында);

вакытлыча эшкә сәләтсез булу буенча пособиеләр турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды);

эшсезлек буенча пособиеләрнең барлык төрләрен түләү (түләүләрнең булмавы) һәм эшсезлекләргә башка төрле түләүләр турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен) (мәшгульлек үзәкләрендә);

тууны дәүләт теркәвенә алу турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (ГХАТ органнарында);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү турында (инвалид балалары булган

гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (җирле үзидарә органнарында);

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (ГХАТ органнарында);

гаилә таркатуны дәүләт теркәвенә алу турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (ГХАТ органнарында);

инвалидка (инвалид балага) айлык акчалата түләү билгеләнү турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

дәүләт хезмәтен алучы белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милекчелек хокукы турында (Дәүләт теркәвенә алу, кадастр һәм картография федераль хезмәтендә (алга таба – Росреестр);

әгәр дәүләт хезмәтен алучы 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен опека (попечительлек) билгеләнүе турында (җирле үзидарә органнарында);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

гражданинның 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килүе турында мәгълүматлар (гражданинның 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Гариза бирүче Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр полрталы аша мөрәҗәгать иткәндә өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына:

мөрәҗәгать итүченең паспорты чын булуын раслау турында белешмәләр (Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында).

Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне

күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, дәүләт бюджетныкы булмаган фондлар органнарыннан, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәткәренең, вәкаләтле оешма хезмәткәренең дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда документаль расланган хаталы яки хокукка каршы килә торган гамәл кылуы (гамәл кылмавы) факты (билгеләре) ачыкланганда, бу хакта дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә.»;

3.4.1 пунктта:

алтынчы абзацта «(хезмәт кенәгәсеннән өземтә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада алынган һәм «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның «Социаль ярдәм чаралары» өлешенә кертелгән белешмәләр.»;

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне сората:

Россия Федерациясе Пенсия Фондыннан барлык дәрәҗә бюджетлардан иминиятләштерелгән затка социаль түләүләр күләме турында;

физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

Россия Эчке эшләр министрлыгына пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында;

Россия Оборона министрлыгына хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособиеләр турында;

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларны дәүләт теркәвенә алу турында, ГХАТ органнарыннан;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында – җирле үзидарә органнарыннан;

гаиләне дәүләт теркәвенә алу турында – ГХАТ органнарыннан;

гаиләне таркатуны дәүләт теркәвенә алу турында – ГХАТ органнарыннан;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында – җирле үзидарә органнарыннан;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында – җирле үзидарә органнарыннан;

опека (попечительлек) билгеләнүе турында – җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен алучы белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында – вәкаләтле органнардан;

аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак урынга милекчелек хокукы турында – Росреестрдан;

мөрәҗәгать итүченең паспорты чын булуын раслау турында – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгыннан, әгәр гариза Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән булса;

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

гражданинның 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килүе турында – Россия

Федерациясе Пенсия фондыннан.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамәләр.».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалану өчен бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарын каплау өчен субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 26 гыйнварындагы 47 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 07.09.2016 № 513, 08.06.2017 № 349, 23.05.2018 № 392, 24.09.2018 № 897 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалану өчен бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарын каплау өчен субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Дәүләт хезмәте алучылар:

пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә булган торышында аталган федераль законнарда күрсәтелгән пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, мөрәҗәгать итү датасына уртача айлык керременең күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннары;

пенсияне башка нигезләрдә алучы яки эше (хезмәте) өчен гомере буе акчалата түләү ала торган, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән, мөрәҗәгать итү датасына уртача айлык керременең күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннары;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, картлык буенча яки эшләгән еллар өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле хезмәт стажы булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә булган торышында аталган федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булган һәм картлык буенча яки эшләгән еллар өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле хезмәт стажы булган, пенсияне башка нигезләрдә алучы яки эше (хезмәте) өчен гомере буе акчалата түләү ала торган, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән затлар.»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге белешмәләрне

раслаучы документлар алына:

чыбыклы телефон элемтәсе (элемтә операторлары) булуы турында;

барлык дәрәҗә бюджетлардан иминиятләштерелгән затка социаль түләүләр күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия фонды);

федераль законнар нигезендә ай саен бирелә торган акчалата түләү алудан баш тарту турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фонды);

эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына күчереп исәпләнгән түләүләрнең һәм бүтән бүләкләүләрнең суммасы турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда күрсәтелгән затларга элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләнгәндә) (Россия Федерациясе Пенсия фонды);

пенсия алу, билгеләү, алмау турында һәм түләүләрне туктату турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда күрсәтелгән затларга элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләнгәндә) (Россия Эчке эшләр министрлыгы);

житештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәжбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда күрсәтелгән затларга элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләнгәндә)(Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды);

эшсезлек буенча барлык төр пособиеләр түләү (түләүләр булмавы) һәм эшсезләргә башка төрле түләүләр турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда күрсәтелгән затларга элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләнгәндә) (Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек үзәге хезмәте дәүләт учреждениеләре) (алга таба – мәшгульлек үзәкләре);

гражданинның 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килүе турында мәгълүматлар (2018 елның 31 декабренә булган торышында күрсәтелгән федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган гражданнарга элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләгәндә) (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнарыннан, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәткәренең, вәкаләтле оешма хезмәткәренең дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда документаль расланган хаталы яки хокукка каршы килә торган гамәл кылуы (гамәл кылмавы) факты (билгеләре) ачыкланганда, бу хакта дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә.»;

3.4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада алынган һәм «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның «Социаль ярдәм чаралары» өлешенә кертелгән белешмәләр.»;

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Элемтә хезмәтләре өчен субсидия билгеләү турында (билгеләүдән баш

тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне сората:

Россия Федерациясе Пенсия Фондыннан барлык дәрәҗә бюджетлардан иминиятләштерелгән затка социаль түләүләр күләме турында;

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

федераль законнар нигезендә ай саен бирелә торган акчалата түләү алудан баш тарту турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

Россия Эчке эшләр министрлыгына пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында;

Россия Оборона министрлыгына хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособиеләр турында;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса;

гражданинның 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килүе турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамәләр.».

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 26 гыйнварындагы 46 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 11.07.2016 № 401, 08.06.2017 № 349, 18.05.2018 № 383, 24.09.2018 № 897 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.2 пунктта:

дүртенче һәм бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә булган торышында аталган федераль законнарда күрсәтелгән пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, мөрәҗәгать итү датасына уртача айлык кеременең күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннары;

пенсияне башка нигезләрдә алучы яки эше (хезмәте) өчен гомере буе акчалата түләү ала торган, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән, мөрәҗәгать итү датасына уртача айлык керемененң күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннары;»;

сигезенче һәм тугызынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, картлык буенча яки эшләгән еллар өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле хезмәт стажы булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә булган торышында аталган федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булган һәм картлык буенча яки эшләгән еллар өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле хезмәт стажы булган, пенсияне башка нигезләрдә алучы яки эше (хезмәте) өчен гомере буе акчалата түләү ала торган, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән затлар.»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге белешмәләрне раслаучы документлар алына:

барлык дәрәҗә бюджетлардан иминиятләштерелгән затка социаль түләүләр күләме турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы дүртенче һәм сигезенче абзацларда күрсәтелгән затларга ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләнгәндә) (Россия Федерациясе Пенсия фонды);

федераль законнар нигезендә ай саен бирелә торган акчалата түләү алудан баш тарту турында (Россия Федерациясе Пенсия фонды);

эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына күчереп исәпләнгән түләүләрнең һәм бүтән бүләкләүләрнең суммасы турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларда күрсәтелгән затларга айлык акчалата түләү билгеләнгәндә) (Россия Федерациясе Пенсия фонды);

пенсия алу, билгеләү, алмау турында һәм түләүләрне туктату турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларда күрсәтелгән затларга ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләнгәндә) (Россия Эчке эшләр министрлыгы);

хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларда күрсәтелгән затларга ай саен бирелә

торган акчалата түләү билгеләнгәндә) (Россия Оборона министрлыгы);

житештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларда күрсәтелгән затларга ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләнгәндә)(Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды);

вакытлыча эшкә сәләтле булмау буенча пособиеләр турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларда күрсәтелгән затларга ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләнгәндә)(Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды);

эшсезлек буенча барлык төр пособиеләр түләү (түләүләр булмавы) һәм эшсезләргә башка төрле түләүләр турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларда күрсәтелгән затларга айлык акчалата түләү билгеләнгәндә) (мәшгульлек үзәкләре);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

гражданинның 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килүе турында мәгълүматлар (2018 елның 31 декабренә булган торышында күрсәтелгән федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган гражданнарга айлык акчалата түләү билгеләгәндә) (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы

күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнарыннан, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәткәренең, вәкаләтле оешма хезмәткәренең дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда документаль расланган хаталы яки хокукка каршы килә торган гамәл кылуы (гамәл кылмавы) факты (билгеләре) ачыкланганда, бу хакта дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә.»;

3.4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада алынган һәм «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның «Социаль ярдәм чаралары» өлешенә кертелгән белешмәләр.»;

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне сората:

Россия Федерациясе Пенсия Фондыннан барлык дәрәҗә бюджетлардан иминиятләштерелгән затка социаль түләүләр күләме турында;

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

федераль законнар нигезендә ай саен бирелә торган акчалата түләү алудан баш

тарту турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

Россия Эчке эшләр министрлыгына пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында;

Россия Оборона министрлыгына хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособиеләр турында;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса;

гражданинның 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килүе турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамәләр.».